Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге
Күн торак пунктындагы Совет урамы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

11 ноябрь, 2025 ел № 5

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең Күн торак пунктында Совет урамында яшәүчеләрнең 2025 елның 11 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 142 (йөз кырык ике).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 79 (җитмеш тугыз).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 79 (җитмеш тугыз).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясындагы 6 өлеше нигезендә гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2026 елда Күн торак пункты Совет урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, 90 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне, көндезге бүлектә укучы студентлар, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- урамнарны яктырту җайланмасы;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (авария хәлендәге агачларны кисү)» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Күн авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Күн авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Баһауов